Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Ялаур авыл җирлегенең Ялаур торак пункты гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

27 **ноябрь 2024 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә», 2024 елның 27 ноябрендә узган: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Ялаур авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидтан тыш, 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 220 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 115 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 115 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Ялаур авыл җирлегенең Ялаур торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Ялаур авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидтан тыш, 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ; мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет «мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/, мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Ялаур авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: О.В.Охотникова

Ялаур авыл җирлеге башлыгы: О.В. Охотникова